СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 352 от 29.04.2020
на № __от ________

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2014 елның 14 ноябрендәге 272 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре буенча белешмәләр бирү турында, шулай ук Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре буенча белешмәләр бирү турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Президентыныц “2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге хисап чорында керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында” 2020 елның 24 апрелендәге УП-250 номерлы Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре буенча белешмәләр бирү турында, шулай ук Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре буенча белешмәләр бирү турында Нигезләмәне раслау хакында”гы 2014 елныц 14 ноябрендәге 272 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре буенча белешмәләр бирү турында, шулай ук Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре,

чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре буенча белешмәләр бирү турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 пунктта “ел саен хисап чорыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча” сүзләрен “ел саен, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү өчен билгеләнгән срокларда” сүзләренә алмаштырырга.

2. Аларны бирү вакыты, Татарстан Республикасы Президентының “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында” гы 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы һәм Татарстан Республикасы Президентының “Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында”гы 2010 елның 11 гыйнварындагы ПУ-4 номерлы Указы белән каралган, 2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге хисап чорында муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, 2020 елның 1 августына кадәр (шул көнне дә кертеп) тапшырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru. рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р. Н. Минниханов